РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

«29» сентября 2022г.

с. Тюлячи

№ 184

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 18 июнендәге 367 номерлы «Теләче муниципаль районында үзәкләштерелгән бухгалтерия җитәкчеләре һәм белгечләренең, муниципаль берәмлекләр Башкарма комитетларының баш бухгалтерлары һәм бухгалтерларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфасына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 2022 елның 09 августындагы 03-16/5606 номерлы хатын карап, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 18 июнендәге 367 номерлы «Теләче муниципаль районында үзәкләштерелгән бухгалтерия җитәкчеләре һәм белгечләренең, муниципаль берәмлекләр Башкарма комитетларының баш бухгалтерлары һәм бухгалтерларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфасына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турында» карары белән расланган Теләче муниципаль районының «Үзәкләштерелгән бухгалтерия» МКУ җитәкчеләренең һәм белгечләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы Нигезләмәнең 3 пунктына үзгәрешләр кертергә һәм яңа редакциядә расларга:

«3. Теләче муниципаль районының «Үзәкләштерелгән бухгалтерия» МКУ җитәкчеләренең һәм белгечләренең вазыйфаи окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Җитәкчеләр һәм белгечләр вазыйфалары | Вазыйфаи оклад, сум<br>Муниципаль учреждение булып торучы үзәкләштерелгән бухгалтерия өчен |
|---|---|
| Муниципаль учреждение җитәкчесе | 27700 |
| Муниципаль учреждение җитәкчесе урынбасары | 25500 |
| Бүлек башлыгы | 21700 |
| Әйдәп баручы бухгалтер | 19300 |
| Бухгалтер | 18000 |

Муниципаль учреждение булып торучы үзәкләштерелгән бухгалтериянең штат расписаниесенә кертү шарты булып, структурада һәрберсендә кимендә 5 берәмлек штатлы 3 бүлек булу тора.

Үзәкләштерелгән бухгалтерия бүлекләренең штат саны кимендә 5 берәмлек булырга тиеш.

2. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 18 июнендәге 367 номерлы «Теләче муниципаль районында үзәкләштерелгән бухгалтерия җитәкчеләре һәм белгечләренең, муниципаль берәмлекләр Башкарма комитетларының баш бухгалтерлары һәм бухгалтерларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфасына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турында» карары белән расланган Теләче муниципаль районы муниципаль берәмлекләре Башкарма комитетларының баш бухгалтерлары һәм бухгалтерларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгәннәрдән тыш) хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турында Нигезләмәнең 3 пунктына үзгәрешләр кертергә һәм яңа редакциядә расларга:

«3. Бухгалтерларның вазыйфаи окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Вазыйфасы | Халык саны түбәндәгечә булган муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары | |
|---|---|---|
| | 3,5 мең кешегә кадәр | 3,5 меңнән артык кеше |
| Баш хисапчы | - | 21000 сум |
| Бухгалтер | 18500 сум | 18500 сум |

3. Әлеге карар 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин